КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 1 ноябрь г.Казань № 997

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын үзгәртеп кору турында» 2019 елның 25 сентябрендәге ПУ-574 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы аппараты хезмәткәрләренең иң чик санын вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен айлык түләү фонды 1 251 195,0 сум күләме белән 57 берәмлек итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына өч министр урынбасарын, шул исәптән бер беренче министр урынбасарын булдырырга рөхсәт ителә.

4. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына 2019 елга Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын тотуга каралган акчалар чикләрендә бу карарны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

5. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип санарга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» дәүләт учреждениесе мәсьәләләре» 2006 ел, 18 апрель, 192 нче карарының 4 нче пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 21 апрель, 199 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 7 ноябрь, 621 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 28 март, 196 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 2 октябрь, 720 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 28 октябрь, 864 нче карарының 5 нче пункты;

«Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыруны оештыру тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 10 декабрь, 1042 нче карарының 2 нче пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары турындагы нигезләмәләргә мобилизация әзерлеге буенча функцияләр кертү хакында» 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче карарының егерме дүртенче – егерме алтынчы абзацлары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 17 март, 197 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль,

318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 13 сенябрь, 762 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 16 март, 221 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 24 март, 237 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 6 август, 668 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 26 декабрь, 1153 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 гыйнвар, 54 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 14 март, 161 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 14 май, 323 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 12 апрель, 238 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль,

318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 8 июль, 471 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы структурасына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 8 август, 575 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 10 август, 578 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 24 декабрь, 969 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 22 гыйнвар, 32 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 15 июнь, 405 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 3 декабрь, 702 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 2 октябрь, 720 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында»

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 14 декабрь, 933 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 2 май, 256 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 21 август, 595 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актлары үз көчен югалткан дип санау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 12 декабрь, 976 нчы карарының 1 нче пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 24 июль, 590 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Граждан хәле актлары язуларының бердәм дәүләт реестрын алып баруның федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәве һәм аларны тапшыру турында белешмәләрне алу функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле органны билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 ел, 20 декабрь, 1196 нчы карарының 3 нче пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 16 февраль, 110 нчы карары.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 1 ноябрь, 997 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы булып тора; ул дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, Татарстан Республикасын цифрлы трансформацияләү, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына дәүләт идарәсе һәм муниципаль идарә функцияләре нигезендә беркетелгән дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне (алга таба – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр) цифрлаштыру, мәгълүмат-коммуникация технологияләре һәм элемтә өлкәләрендә билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында норматив хокукый җайга салу, Татарстан Республикасының дәүләт сәясәтен эшләү функцияләрен гамәлгә ашыра.

Министрлык мәгълүмат иминлеген (шул исәптән бик мөһим мәгълүмат инфраструктураларын) тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы булып тора.

1.2. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә бу Нигезләмәнең кушымтасында күрсәтелгән эшчәнлек төрләре буенча эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыра.

1.3. Министрлык үз эшчәнлеген турыдан-туры һәм Министрлыкның ведомство буйсынуындагы оешмалары аша гамәлгә ашыра.

1.4. Министрлык үз эшчәнлеген федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек итеп гамәлгә ашыра.

1.5. Министрлык үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.6. Министрлык юридик зат булып тора, аның мөстәкыйль балансы, банк учреждениеләрендә исәп-хисап счеты һәм башка счетлары, үз исеме язылган һәм Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте төшерелгән мөһере бар.

Министрлыкның кыскартылган исеме – ТР Цифр министрлыгы.

1.7. Министрлык үз вәкаләтләрен тормышка ашырганда эшчәнлекнең

билгеләнгән өлкәсендәге товар базарларында конкуренцияне үстерү буенча максатларның һәм бурычларның өстенлеген тәэмин итә.

1.8. Министрлыкның урнашу урыны: 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кремль урамы, 8 нче йорт.

## 2. Министрлыкның бурычлары

2.1. Министрлыкның төп бурычлары:

2.1.1. Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, Татарстан Республикасын цифрлы трансформацияләү, дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне цифрлаштыру, мәгълүмат иминлеген тәэмин итү, мәгълүмат-коммуникация технологияләре һәм элемтә өлкәләрендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру;

2.1.2. Дәүләт идарәсе өлкәсендәге процессларны үтәли ведомствоара цифрлаштыруны һәм платформа хәл ителешләрен гамәлгә кертүне тәэмин итү;

2.1.3. Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре базасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм һәркем өчен аннан файдалану мөмкинлеген арттыру;

2.1.4. Татарстан Республикасы территориясендә «Россия Федерациясенең цифрлы икътисады» илкүләм программасын тормышка ашыруны оештыру;

2.1.5. Татарстан Республикасы территориясендә перспективалы мәгълүмат-коммуникация технологияләрен һәм стандартларны гамәлгә кертүгә булышлык күрсәтү;

2.1.6. Татарстан Республикасы халкының, дәүләт хакимияте органнары һәм оешмаларының элемтә хезмәтләреннән, мәгълүмат ресурсларыннан файдалану мөмкинлегенә һәм мәгълүмати үзара хезмәттәшлеккә ихтыяҗын тәэмин итү;

2.1.7. Татарстан Республикасы территориясендә хезмәтләр күрсәтүче барлык мәгълүматлаштыру һәм элемтә операторларына конкурентлык мохитен үстерү өчен тигез хокуклы нигездә уңайлы шартлар тудыру.

## 3. Министрлыкның функцияләре

3.1. Министрлык түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җаваплы:

3.1.1. Мәгълүматлаштыру белән идарә итү (01.15*), шул исәптән:

3.1.2. Татарстан Республикасының ведомство дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.2*);

3.1.3. Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү (дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итүдән тыш) (01.15.02*);

3.1.4. Элемтә белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү (03.04*).

3.2. Министрлык түбәндәгеләр белән үзара хезмәттәшлек итә:

---

*Код билгеләмәсе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторы нигезендә бирелә.

3.2.1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар әзерләү эшчәнлеген яраштыру (шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килү-килмәвен тикшерүдә тоту) (02.04.01*);

республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03*);

3.2.2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән урта һөнәри белем бирү белән (федераль белем бирү оешмаларында алына торган белемнән тыш) билгеләнгән тәртиптә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.05.06*);

3.2.3. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01*);

3.2.4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез мөлкәтне (биналар, корылмаларны), транспортны, җиһазларны, мәдәни мирас объектларын файдалану белән идарә итү (01.07.01*);

Татарстан Республикасы милкендәге акцияләр пакетын (өлешләрне) файдалану белән идарә итү (01.07.02*);

киңлек мәгълүматлары белән идарә итү (01.07.04.3*);

3.2.5. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәтне саклау белән идарә итү функцияләрен гамәлгә ашырганда (01.13.02*);

3.2.6. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән социаль-икътисадый программалар эшләү функцияләрен гамәлгә ашырганда (01.01*);

3.2.7. Татарстан Республикасының Архив эшләре буенча дәүләт комитеты белән архив эшләре белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.03*);

3.2.8. Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты белән социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.01.1*);

3.2.9. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы белән дәүләт-шәхси партнерлык һәм шәхси инвестицияләр өлкәсендә инвестиция эшчәнлеген үстерү белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.18*);

3.2.10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе белән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлеге белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.08*);

3.2.11. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә дәүләт идарәсе функциясен гамәлгә ашырганда.

3.3. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә түбәндәге вәкаләтләрне

гамәлгә ашыра:

3.3.1. Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү өлкәсендә:

3.3.1.1. Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе һәм муниципаль идарә органнары эшчәнлеген һәм төп икътисад тармакларын цифрлаштыруга методик, оештыру, техник һәм мәгълүмати-аналитик яктан булышлык күрсәтү эшен оештыра;

3.3.1.2. Татарстан Республикасы территориясендә «Россия Федерациясе цифрлы икътисады» илкүләм программасын гамәлгә кертү чаралары комплексын тормышка ашыра;

3.3.1.3. Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне цифрлаштыру эшен оештыра;

3.3.1.4. Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәген үстерүне оештыра;

3.3.1.5. Цифрлы трансформацияләү һәм цифрлы технологияләр өлкәсендә бизнес-бергәлек, фәнни-мәгариф һәм башка бергәлекләр белән үзара хезмәттәшлек итә;

3.3.1.6. Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү стандартларын эшләүдә (шул исәптән заманча үзара хезмәттәшлек интерфейсларын эшләүне кертеп) катнаша;

3.3.1.7. Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасының мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат ресурсларын булдыруны, үстерүне, эксплуатацияләүне тәэмин итә;

3.3.1.8. Татарстан Республикасында дәүләт идарәсе һәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү барышларын оптимальләштерү максаты белән мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат технологияләрен файдалану буенча тәкъдимнәр әзерләү һәм анализ ясау;

3.3.1.9. Татарстан Республикасының дәүләт идарәсен һәм муниципаль идарәне һәм төп икътисад тармакларын цифрлы трансформацияләү өлкәсендә ведомство проект офисы эшчәнлеген һәм үсешен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итә;

3.3.2. Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә:

3.3.2.1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, оешмаларының мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге законнар нигезендә ведомствоара хезмәттәшлеген оештыра;

3.3.2.2. Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат-коммуникация инфраструктурасы төзелешенең бердәм технологик архитектурасын эшләүне оештыра;

3.3.2.3. Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-коммуникация инфраструктурасы элементларын булдыру, эксплуатацияләү һәм модернизацияләү өлкәсендә бердәм стандартлар һәм технологик сәясәт эшләүне оештыра;

3.3.2.4. Татарстан Республикасында мәгълүмат иминлеге тотрыклылыгын һәм эшләвен тәэмин итүне исәпкә алып, дәүләт идарәсе системасын цифрлы нигездә үстерү һәм мәгълүмат технологияләре өлкәсендә техник сәясәтне тормышка ашыра;

3.3.2.5. Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының мәгълүмат иминлеген тәэмин итү эшен оештыра;

3.3.2.6. Дәүләт сере яки закон белән саклана торган башка сер булып торган мәгълүматларны саклауны тәэмин итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм яраштыра;

3.3.2.7. Мәгълүмат иминлеге торышын бәяләүне, мәгълүматка куркыныч янауларны фаразлауны һәм ачыклауны, аларны булдырмау һәм аларның барлыкка килү нәтиҗәләрен бетерү буенча өстенлекле юнәлешләрне билгеләүне, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында һәм Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнарында мәгълүмат иминлеген тәэмин итү буенча чаралар комплексын планлаштыруны, башкаруны һәм бәяләүне тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

3.3.2.8. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) булдыру, аларны файдалану һәм сатып алу чараларын планлаштыру кысаларында кулланыла торган документларга эксперт бәяләмәсен үткәрә;

3.3.2.9. Татарстан Республикасы территориясендә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен, шул исәптән «Интернет» челтәрен нәтиҗәле файдалану өчен шартлар тудыра;

3.3.2.10. Мәгълүмат технологияләре тармагын үстерүгә булышлык күрсәтә торган стратегик башлангычларны эшләүне һәм тормышка ашыруны башкара;

3.3.2.11. Татарстан Республикасы территориясендә мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә инфраструктураның ышанычлылыгын, тотрыклылыгын һәм эшләү иминлеген тәэмин итә;

3.3.2.12. Мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә инфраструктура эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруны һәм тармакның инвестицион җәлеп итүчәнлеген тәэмин итә;

3.3.2.13. Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру программасы чаралары кысаларында тормышка ашырыла торган өстенлекле проектлар исемлеге буенча тәкъдимнәр әзерли;

3.3.2.14. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат үзәген – мәгълүмат системасын оештыру, үстерү һәм эксплуатацияләү эшләрен яраштыруны гамәлгә ашыра;

3.3.2.15. «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексы булдыруны һәм аның эшләвен тәэмин итә;

3.3.2.16. Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә, дәүләт-шәхси партнерлык инструментларыннан файдаланып, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат технологияләрен эшләү һәм/яки модернизацияләү өлкәсендә эшләрне яраштыруны гамәлгә ашыра;

3.3.2.17. Мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә кабул ителгән Татарстан Республикасы программаларын тормышка ашыру нәтиҗәлелегенә анализ ясый һәм аларга билгеләнгән тәртиптә кирәкле үзгәрешләрне кертә;

3.3.2.18. Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары прототипларын булдыруны һәм тестлауны гамәлгә ашыра;

3.3.2.19. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль бюджет һәм бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетлары акчасы хисабына булдырыла һәм сатып алына торган мәгълүмат системаларын исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат

системасы турында» 2012 елның 26 июнендәге 644 номерлы карары нигезендә эшли торган федераль бюджет һәм бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетлары акчасы хисабына булдырыла һәм сатып алына торган мәгълүмат системаларын исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы базасында Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрын алып баруны гамәлгә ашыра;

3.3.2.20. Граждан хәле актлары язуларының бердәм дәүләт реестрын алып бару буенча федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлар ала һәм аларны «Граждан хәле актлары турында» 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль законның 13.2 статьясы нигезендә вәкаләтле органнарга һәм оешмаларга тапшыра;

3.3.3. Элемтә өлкәсендә:

3.3.3.1. Татарстан Республикасының телекоммуникация инфраструктурасын үстерү перспективаларын билгели, аларның өстенлеге булып Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнарының, шулай ук юридик һәм физик затларның элемтә хезмәтләренә ихтыяҗларын канәгатьләндерү тора;

3.3.3.2. Татарстан Республикасы территориясендә элемтә челтәрләренең торышын һәм үзара бәйләнешен мониторинглауны һәм анализлауны гамәлгә ашыра һәм элемтә операторлары катнашында элемтә челтәрен үстерү концепциясен, программаларын эшли һәм аларны тормышка ашыруны яраштыра;

3.3.3.3. Федераль һәм республика телевидение тапшырулары һәм радио тапшырулары системаларын үстерү проектларын тормышка ашыруны, шул исәптән цифрлы технологияләргә күчерүне гамәлгә ашыра;

3.3.3.4. Элемтә чараларын үстерү һәм камилләштерү, яңа технологияләрне һәм хезмәт күрсәтүләрне үстерү, күрсәтелә торган хезмәтләрнең югары сыйфатлы булуын тәэмин итү һәм барлык кулланучылар өчен алардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү буенча техник сәясәт үткәрә һәм аны тормышка ашыра;

3.3.3.5. Элемтә челтәрен үстерү һәм эксплуатацияләү буенча элемтә операторларының үзара хезмәттәшлеген законнар белән күздә тотылган тәртиптә яраштыруны гамәлгә ашыра һәм элемтә чараларының ышанычлылыгын арттыру һәм сыйфатын яхшырту, шул исәптән аларның эшләү тотрыклылыгын арттыру буенча чаралар эшли;

3.3.3.6. Татарстан Республикасы территориясендә почта элемтәсе объектлары челтәрен үстерүдә катнаша;

3.3.3.7. Татарстан Республикасы территориясендә почта элемтәсе оешмасы өчен исемле әйберләр куллану һәм почта түләвенең дәүләт билгеләрен тарату эшчәнлеген яраштыра;

3.3.3.8. Татарстан Республикасы территориясендә махсус чорда һәм гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгәндә Россия Федерациясенең бердәм электр элемтәсе челтәрен торгызу чараларын яраштыра;

3.3.3.9. Татарстан Республикасының элемтә челтәрләрендә һәлакәтләрне һәм зыян салуларны бетерү буенча элемтә операторлары хезмәттәшлеген законнар белән билгеләнгән тәртиптә яраштыруны гамәлгә ашыра;

3.3.3.10. Статистика мәгълүматларын җыюны гамәлгә ашыра, анализ үткәрә, Россия Федерациясе Цифрлы нигездә үстерү, элемтә һәм массакүләм

коммуникацияләр министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Статистика буенча дәүләт комитетына кертү өчен хисаплар төзи;

3.3.3.11. Татарстан Республикасы территориясендә таныклаучы үзәкләр тарафыннан бирелгән имзалар ачкычлары сертификатларындагы әлеге үзәкләрнең вәкаләтле затларының электрон имзаларын раслауны оештыра;

3.3.3.12. Татарстан Республикасы территориясендә таныклаучы үзәкләрнең имзалар ачкычлары сертификатларының бердәм дәүләт реестрын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтле затларының имзалар ачкычлары сертификатлары реестрын алып баруны, шулай ук гражданнар, оешмалар, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының алардан файдалана алуын тәэмин итүне оештыра;

3.3.3.13. Министрлыкның, эшчәнлеге Министрлык эшчәнлегенә бәйле яки аның карамагы өлкәсендәге оешмаларның мобилизация әзерлеген һәм мобилизациясен оештыра һәм тәэмин итә;

3.3.4. Башкалар:

3.3.4.1. Гражданнарны кабул итүне оештыра, гражданнарның телдән һәм язма мөрәҗәгатьләрен үз вакытында һәм тулысынча карап тикшерүне, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җавапларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән вакытта җибәрүне тәэмин итә.

3.3.4.2. Дәүләт идарәсе системасын цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә өлкәсендә норматив хокукый базаны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли һәм аларны билгеләнгән тәртиптә кертә, шул исәптән законнар чыгару һәм башка норматив хокукый актлар проектларын эшли;

3.3.4.3. Министрлыкка бирелгән вәкаләтләр чикләрендә мәгълүмат технологияләре һәм элемтә өлкәсендә халыкара оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итә;

3.3.4.4. Эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә ведомство бүләкләрен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә куя һәм бу бүләкләр белән әлеге өлкәдә эшләүче хезмәткәрләрне бүләкли;

3.3.4.5. Хезмәтне саклау һәм экология иминлеге өлкәсендә дәүләт сәясәте тармагында тормышка ашыруны оештыра, хезмәтне саклау хезмәтләре белән методик җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра, хезмәтне саклау кагыйдәләре һәм нормалары үтәлешенә ведомство тикшерүен оештыра һәм гамәлгә ашыра, җитәкчеләрнең, шулай ук тармак оешмаларында хезмәтне саклау өчен җаваплы башка вазыйфаи затларның укуын оештыра;

3.3.4.6. Татарстан Республикасында мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә конгресслар, конференцияләр, семинарлар, күргәзмәләр һәм башка чаралар оештыра;

3.3.4.7. Оешмаларга Министрлык компетенциясендәге мәсьәләләр буенча кирәкле методик һәм консультация ярдәме күрсәтә;

3.3.4.8. Үз компетенциясе чикләрендә Россия Федерациясе Хөкүмәте белән расланган Россия Федерациясендә хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру методикасы нигезендә Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингын һәм Министрлык эшчәнлеге өлкәсендә законнар мониторингын гамәлгә ашыра;

3.3.4.9. Министрлык эшчәнлеге барышында барлыкка килгән архив

документларын комплектлау, саклау, исәпкә алу һәм файдалану эшен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашыра;

3.3.4.10. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында тәкъдим ителгән сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга сарыф ителгән эфир вакыты күләмен исәпкә алуны гамәлгә Ашыра

3.3.4.11. Ел саен 1 февральгә Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының вәкаләтле органына коррупциягә каршы сәясәт чараларын тормышка ашыру турында хисап кертә;

3.3.4.12. Татарстан Республикасының ведомство буйсынуындагы дәүләт казна, бюджет һәм автоном учреждениеләрен (алга таба – учреждениеләр) гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыра, шул исәптән:

учреждениеләр оештыру, аларны үзгәртеп оештыру, аларның тибын үзгәртү, аларны бетерү турында тәкъдимнәр һәм карарлар проектларын әзерли, аларның уставларын раслый һәм аларга үзгәрешләр кертә;

учреждениеләр өчен учреждение уставы белән күздә тотылган эшчәнлекнең төп төрләре нигезендә юридик һәм физик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыра һәм раслый;

учреждениеләрне гамәлгә куючының башка функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

3.3.4.13. Татарстан Республикасының мәгълүмат технологияләре һәм элемтә тармагы предприятиеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә функциональ анализ ясауны һәм тармак аудитын үткәрүне оештыра;

3.3.4.14. Министрлыкка йөкләнгән вәкаләтләр чикләрендә билгеләнгән тәртиптә килешүләр һәм шартнамәләр төзи, шулай ук әлеге шартнамәләр, килешүләр һәм федераль башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, башка Россия һәм чит ил органнары һәм оешмалары белән үз компетенциясе нигезендә төзелгән гавами-хокукый характердагы башка актлар реестрын алып бара;

3.3.4.15. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары проектларын эшли;

3.3.4.16. Ел саен ведомство буйсынуындагы учреждениеләр тарафыннан фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең билгеләнгән сыйфат стандартларына туры килү-килмәвенә бәя бирә;

3.3.4.17. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлегенең дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килү-килмәвенә бәя бирә;

3.3.4.18. «Татарстан Республикасында яшәүче картасы» проектын тормышка ашыруда катнашучы кредит оешмаларына Татарстан Республикасында яшәүчеләр карталары реестрының веб-сервисыннан һәм Татарстан Республикасында яшәүче картасын чыгару (яңадан чыгару) өчен кирәкле мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген бирә;

3.3.4.19. Татарстан Республикасының мәгълүмат ресурсларын формалаштыра һәм эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә файдалана;

3.3.4.20. Тармакта кадрлар әзерләү сәясәтен тормышка ашыра, шул исәптән:

тармакны кадрлар белән тәэмин итү торышын өйрәнә һәм анализлый;

тармакның башлангыч, урта һәм югары һөнәри белем бирү һөнәрләре һәм белгечлекләре буенча квалификацияле эшчеләр һәм белгечләр әзерләүгә ихтыяҗы булу фаразын формалаштыруны оештыра;

Татарстан Республикасының фәнни-белем бирү кластерларында белгечләр әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү өчен дәүләт заказына тәкъдимнәр формалаштыра;

тармакка хезмәт ресурсларын җәлеп итү һәм аларны эш белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә компетентлыгын үстерү буенча чаралар оештыра;

3.3.4.21. Министрлык ихтыяҗларын, шулай ук эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә башка дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра;

3.3.4.22. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау өчен Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә аның компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча телдән һәм язма рәвештә хокукый консультацияләр рәвешендә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтә;

3.3.4.23. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә чараларын гамәлгә ашыра;

3.3.4.24. Министрлык эшчәнлеге өлкәсендә кирәкле тикшеренүләр оештыра;

3.3.4.25. Федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә социаль ярдәмгә һәм социаль яклауга мохтаҗ гражданнарга гаризалар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм хокукый характердагы башка документлар төзү рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә һәм судларда, дәүләт һәм муниципаль органнарда, оешмаларда граждан мәнфәгатьләрен кайгырта;

3.3.4.26. Үз компетенциясе чикләрендә экстремистлык эшчәнлегенә һәм терроризмга каршы көрәштә катнаша, Министрлыкка беркетелгән объектларның террорчылыкка каршы саклануын тәэмин итә;

3.3.4.27. Үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне мониторинглауның һәм дини һәм милли нигездә низагларны алдан кисәтүнең комплекслы системасы кысаларында мәгълүмат җыюны һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына кертүне гамәлгә ашыра;

3.3.4.28. Терроризмга каршы тору чараларын тормышка ашырганда өйрәнүләр үткәрүдә катнаша.

## 4. Министрлыкның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Министрлык түбәндәгеләргә хокуклы:

4.1.1. Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә өлкәсендә эшләүче дәүләт предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләре кандидатуралары турында Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә;

4.1.2. Тармак хезмәткәрләрен Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертергә;

4.1.3. Дәүләт вәкилләренә кандидатуралар сайлауны һәм алар турындагы тәкъдимнәрне Хуҗалык җәмгыятьләренең идарә органнарында дәүләт вәкилләре белән эшләү буенча ведомствоара комиссиягә кертүне гамәлгә ашырырга;

4.1.4. Республика һөнәр берлеге комитеты белән тармак тариф килешүе төзергә;

4.1.5. Татарстан Республикасының дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итү өчен шартнамә нигезендә фәнни оешмалар, галимнәр һәм белгечләр (шул исәптән чит илләрдән) җәлеп итәргә;

4.1.6. Министрлыкка Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән беркетелгән башка хокукларны һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга.

4.2. Министрлык түбәндәгеләргә бурычлы:

4.2.1. Үз эшчәнлеген Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырырга;

4.2.2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан ел саен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органына идарә итүгә дәүләт йөкләмәсе составында билгеләнә торган Министрлык эшчәнлеген бәяләү индикаторларына ирешүне тәэмин итәргә;

4.2.3. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләрен һәм дәүләт граждан хезмәте мәсьәләләре буенча башка норматив хокукый актларны тормышка ашыруны тәэмин итәргә.

## 5. Министрлык эшчәнлеген оештыру

5.1. Министрлыкның башында министр тора, ул Татарстан Республикасы Конституциясе белән билгеләнгән тәртиптә вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә.

Министр урынбасарлары министр тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә.

5.2. Министрлык үз карамагындагы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә мәсьәләләре буенча иҗтимагый яраштыру советының оештыру эшчәнлеген тәэмин итә.

5.3. Министр:

Министрлык эшчәнлегенә шәхси идарә нигезендә гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра һәм Министрлыкка йөкләнгән бурычларның үтәлеше һәм эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру өчен шәхси җавап бирә;

Министрлык структурасына керә торган структур бүлекчәләр турындагы нигезләмәләрне раслый, Министрлык аппараты хезмәткәрләрен вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә, министр урынбасарлары арасында йөкләмәләрне бүлә;

үз компетенциясе чикләрендә боерыклар (күрсәтмәләр) чыгара, аларның үтәлешен тикшерүдә тотуны оештыра;

хезмәткәрләрнең билгеләнгән саны, хезмәт өчен түләү фонды һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә штат расписаниесен, Министрлык аппаратын тотуга чыгымнар сметасын раслый;

министр урынбасарлары, Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлегенең төп күрсәткечләре исемлеген раслый;

боерык белән Министрлыкка беркетелгән функцияләр процесслары (ярдәмче процесслары) үтәлеше стандартларын раслый;

эшчәнлек нәтиҗәлелегенең ирешелгән күрсәткечләренә карап, стимуллаштыра торган түләүләр күләмен исәпләү тәртибен билгеләү турындагы нигезләмәне раслый;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләре белән хезмәт законнары һәм Министрлык өчен билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре нигезендә шартнамәләр (хезмәт шартнамәләренә өстәмә килешүләр) төзи.

5.4. Министрлык тарафыннан коллегия төзелә, аның төп бурычы – дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә өлкәсендә дәүләт идарәсе функцияләрен гамәлгә ашыруга бәйле мөһим мәсьәләләр буенча карарлар эшләү. Коллегия составына министр, аның урынбасарлары, дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә өлкәсендәге вәкаләтле органнар, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары җитәкчеләре, Министрлыкның иҗтимагый советы рәисе, оешмалар, шул исәптән фәнни оешмалар җитәкчеләре керә.

Коллегия составы һәм саны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

Коллегиянең рәисе министр була.

5.5. Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү министр боерыгы белән расланган эшчәнлек нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.6. Министрлык үзгәртеп оештырылганда архив документлары (идарә, финанс-хуҗалык, шәхси состав буенча документлар, вакытлыча саклана торган документлар) тәртипкә салынган хәлдә хокук дәвамчысына тапшырыла.

Министрлык бетерелгәндә Татарстан Республикасының Архив фонды документлары, шәхси состав буенча документлар, шулай ук вакытлыча саклау вакыты чыкмаган документлар тәртипкә салынган хәлдә Татарстан Республикасының Дәүләт архивына саклауга тапшырыла.

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә кушымта


Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының оешмалар һәм учреждениеләр белән үзара хезмәттәшлек итә торган икътисадый эшчәнлек төрләре исемлеге

| Икътисадый эшчәнлек төрләре кодлары билгеләмәсе* | Икътисадый эшчәнлек төрләре исеме |
|---|---|
| 26.2 | Компьютерлар һәм периферия җиһазлары җитештерү |
| 26.3 | Коммуникация җиһазлары җитештерү |
| 53 | Почта элемтәсе эшчәнлеге һәм курьерлык эшчәнлеге |
| 58.2 | Программа тәэминатын эшләп чыгару |
| 61 | Телекоммуникацияләр өлкәсендә эшчәнлек |
| 62 | Компьютер өчен программа тәэминаты эшләү, бу өлкәдә консультация хезмәтләре һәм башка иярчен хезмәтләр күрсәтү |
| 63 (63.12.1, 63.91, 63.99.2 башка) | Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә эшчәнлек |
| 95.1 | Компьютерлар һәм коммуникация җиһазларын ремонтлау |

*Икътисадый эшчәнлек төрләре кодлары билгеләмәсе Федераль техник җайга салу һәм метрология агентлыгының 2014 елның 31 гыйнварындагы 14-ст номерлы боерыгы белән расланган Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы. 029-2014 нче гомумроссия классификаторы (Европа бергәлегендә эшчәнлек классификациясе, 2 нче редакция) нигезендә бирелә.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 1 ноябрь, 997 нче
карары белән расланды

## Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы структурасы




---